Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге составына керүче Бирдебәк авыл җирлегендә гражданнар җыены

# КАРАРЫ

15 ноябрь 2019 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Казаклар Чаллысы авыл җирлеге составына керүче Бирдебәк авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Бирдебәк авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- Бирдебәк авылындагы Клуб урамы юлларын ремонтлау;
- Бирдебәк авылындагы Бөек Ватан сугышында катнашучылар истәлегенә куелган Һәйкәлне койма белән әйләндереп алу;
- кышкы чорда Бирдебәк авылындагы юлларны карап торуга;

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Казаклар Чаллысы авылы, Иванов урамы, 26 йорт, Иванай авылы, Калинин урамы,18 йорт; Бирдебәк авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт;Үри Чаллысы авылы, Гаврилов урамы, 24 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Ананьев И.С.

Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы: Ананьев И.С.